Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы
«Апаз балалар бакчасы » муниципаль бюджет
мәктәпкәчә белем бирү учреждениесе

4 сан
Февраль
2025



# ЧИШМӘ БАШЫ

Бакчабызның бүгенгесен яктыртучы мәгълүмати электрон газетасы

Газетаның сәхифәсе;

*2025 ел ватанны саклаучылар елы.
* Җиңүнең 80 еллыгы.
* Әтиләребез бездә кунакта.

Баш мөхәррир- бакча мөдире : Зайнуллина Индира Тәлгать кызы
Мөхәррир урынбасары тәрбияче: Нигъмәтҗанова Лилия Гаптеләхәт кызы.

# *2025 ел –Ватанны саклаучылар елы*

2025 ел Россиядә ватанны саклаучылар елы дип игълан ителде.Мондый тәкьдим белән Россия президенты В.В Путин гаиләләргә ярдәм итү буенча Дәүләт Советында чыгыш ясады. Быел без Бөек җинүнең 80 еллыгын билгеләп үтәбез.шуна бәйле рәвештә 2025 –елны “Ватанны саклаучылар” елы дип игълан ителде. Безнең геройлар һәм махсус хәрби операциядә катнашучылар хөрмәтенә һәм Ватанны өчен төрле тарихи чорларда сугышкан ата-бабаларыбызның батырлыклары истәлегенә. Нацизмны җиңгән Этиләребез, бабаларыбыз даны өчен , - диде В.В.Путин.

Быел тарихның төрле чорларында Ватан өчен көрәшкән барлык кешеләрнең батырлыгына, шулай ук хәзерге геройларга – махсус хәрби операциядә катнашучыларга хөрмәт күрсәтү булачак.

# *Жиңүнең 80 еллыгы*

***2025 елда ботен илебез белән иң зур бәйрәм- совет халкынын Бөек Ватан сугышында җиңүенә 80 ел тулуны билгеләп үтәчәкбез. Бу җиңү, һич арттырмыйча әйткәндә - безнен иң зур горурлыгыбыз. Җиңүчеләр алдында без түләп бетерә алмаслык бурычлы. Бугенге көндәге унышларыбыз ветераннарыбызның җиңү хакына фронтта фидакарьләрчә көрәшүе һәм тылда тырышып эшләве нәтиҗәсендә ирешелде. Җиңүнең 80 еллыгын бәйрәм итүнең рәсми логотибы расланды.Аны Мәскәүдәге Поклон тавындагы җиңү музеенда тәкъдим иткәннәр. Логотипнын монумент символы Волградта Мамай курганында урнаштырылган. “Ватан ана чакыра”! монументы скульптор Е.В.Вучетич тарафыннан эшләнгән. Ул көрәшкә өндәү рәвешендә- кылыч тоткан хатынны сүрәтли. Үз улларын һәм кызларын дошманга каршы сугышка чакыручы Ватан-Ана образы халкыбызның какшамас рухы символы булып тора.***


2025 ЕЛ · ВАТАННЫ
САКЛАУЧЫЛАР ЕЛЫ


ГОРДИТСЯ АРМИЕЙ
СТРАНА...


2025
ВАТАННЫ
САКЛАУЧЫЛАР
ЕЛЫ
80

# *Әтиләребез бездә кунакта.*

23 февраль –Ватанны саклаучылар көне белән барлык әтиләрне, абыйларны, бабайларны бәйрәм белән котлыйбыз!Безнең бабайларыбыз, әтиләребез илебез имин, тыныч булсын өчен Ватаныбызны саклаганнар.Әти кеше- гаилә башлыгы аңа зур ихтирам, олы хөрмәт белән караганнар.Ә бүген алар бәйрәмебезнең кадерле кунаклары. Ә бүген бәйрәмдә әтиләребез, бабайларыбыз үз балаларының җырларын, биюләрен, матур шигырьләрен тынладылар. Балалар үз куллары белән ясалган бүләкләре белән әтиләрен, бабайларын котладылар. Әтиләр гаиләнең яклаучысы, саклаучысы, ышанычы.






НАШИ ЗАЩИТНИКИ!
с 23 февраля!




НАШИ ЗАЩИТНИКИ!
с 23 февраля!